**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**Сарман авыл җирлеге**
**423350 Сарман авылы, Ленин ур.,52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: Sar.sar@tatar.ru**

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.Ленина,52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sar.sar @tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**31 март 2025 ел** **№ 10**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 174.3 статьясы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү уздыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә 1 апрельгә кадәр Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге башкарма комитетына хисап елындагы һәм хисап елына кадәрге елдагы һәр салым чыгымы буенча белешмәләр җибәрүне тәкъдим итәргә:

- ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны турында;
- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге бюджетының төшеп кала торган керемнәре суммалары турында;
- салым чыгымнарын стимуллаштыручыларга карата һәр салым чыгымы буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге бюджетына түләүчеләр тарафыннан түләү өчен декларацияләнгән салымнар күләме турында

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Сарман авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Л.И.Шәрипова